БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

9 февраля 2023 ел № 168

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Урта Көшкәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында**

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлеге территориясен шәһәр төзелеше планлаштыруын гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 32 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14,15 статьяларына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставына таянып, гавами тыңлаулар һәм килештерү комиссиясе нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Урта Көшкәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен расларга.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлеге башкарма комитетына:

- әлеге карарның 1 пункты белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Урта Көшкәт авыл җирлеге» муниңипаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашырырга;
- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Урта Көшкәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында карарны Территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасына кертүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны baltasi.tatarstan.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин